**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЗАРЕЧЕНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ЗАРЕЧНЫЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

423008, РТ, Нурлатский район п. Заречный,
ул. Черемшанская, д.5

Чирмешән ур., 5нче йорт, ТР,
Нурлат районы, Заречный пос.,
423008

Телефон: 8 (84345) 38613, факс 38613 E-mail: Zarech.Nur@tatar.ru, сайт: http://nurlat.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

21.03.2023 ел № 3

Нурлат муниципаль районы Заречный авыл җирлеге территориясендә кулланылган терекөмешле лампаларны туплау урыны турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 28 декабрендәге 2314 номерлы карары белән расланган, яктырту җайланмалары, электр лампалары өлешендә кулланылучы һәм тиешле җыймау, туплау, куллану, зарарсызландыру, транспортлау һәм урнаштыру аркасында гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә һәм әйләнә-тирә мохиткә зыян китерергә мөмкин булган җитештерү калдыклары белән эш итү Кагыйдәләре нигезендә, (алга таба - Кагыйдәләр) Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Заречный авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Кулланылган терегөмешле лампаларны туплау урыннарын шул исәптән мондый туплану урыннарын оештыру Кагыйдәләрнең 5 пункты нигезендә күпфатирлы йортларда туплану урыннарын оештыру өчен биналар булмау сәбәпле мөмкин булмаган очракта, әлеге карарга кушымта нигезендә билгеләргә.

2. Кулланучыларга туплану урыннары турында мәгълүмат бирү түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендлары аша башкарыла:

Татарстан Республикасы, Нурлат районы, Заречный пос., Үзәк ур., 1нчы й.;
Татарстан Республикасы, Нурлат районы, Торнаяз, Лесная ур., 26нчы й.;
Татарстан Республикасы, Нурлат районы, Юган пос., Осиновая Роща ур., 13нче й.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә һәм httr://pravo.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталында, шулай ук Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында урнаштырылырга тиеш. http://nurlat.tatarstan.ru/.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Заречный авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе Т.В. Забойдулина

Нурлат муниципаль районы
Заречный авыл җирлеге башкарма комитетының 2023 елның 21 мартындагы 3 номерлы карарына кушымта

Нурлат муниципаль районы Заречный авыл җирлеге территориясендә эшкәртелгән терекөмешле лампаларны туплау урыны

| N т/с | Бина урыны | Адресы |
|---|---|---|
| 1 | Заречный авыл җирлеге башкарма комитеты бинасы | Татарстан Республикасы, Нурлат районы, Заречный пос, Чирмешән ур., 5нче й.<br>(тел.8-84345-38613) |